КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 июль г.Казань № 864

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы; 2016 ел, 19 май, 323 нче; 2016 ел, 3 сентябрь, 613 нче; 2018 ел, 14 апрель, 245 нче; 2019 ел, 7 май, 383 нче; 2019 ел, 12 сентябрь, 821 нче; 2021 ел, 31 май, 396 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1020 нче; 2022 ел, 22 февраль, 155 нче; 2022 ел, 7 июнь, 533 нче, 2022 ел, 20 июль, 701 нче, 2022 ел, 5 октябрь, 1069 нчы, 2023 ел, 26 гыйнвар, 48 нче, 2023 ел, 17 март, 266 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы Указы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә,

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары» сүзләрен «башка республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

егерме өченче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары аппаратлары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары аппаратлары» сүзләренә алмаштырырга;

илле бишенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коллегия составына министр (коллегия рәисе), аның вазыйфасы буенча урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар вәкилләре керә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин